**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авылында гражданнар җыены карары**

21 ноябрь 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елда Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзүгә, ремонтлау, карап тотуга; - Татар Буасы авылында торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабуга (ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәт өчен түләү һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтү) ; - ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (инвентарь сатып алу) юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,

Татар Буасы авыл җирлеге башлыгы __________ Р.Ф.Йосыпов

Халык җыены секретаре __________ Р.Р.Камалетдинова